ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТМУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_22.03.2021__ М ө с л и м №__123__

# Мөслим муниципаль районы һәм Мөслим авылы буенча 2003 елда туган һәм хәрби хезмәткә чакырылудан кичектерелү вакыты чыккан зурррак яшьтәге гражданнарга язгы чакырылыш үткәрү турында

Мөслим һәм Мөслим муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә вакытында һәм оешкан төстә чакыру максатыннан, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 23 ст., 24 ст., 25 ст., 26 ст., 27 ст., 28 ст., «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы һәм Мөслим авылы буенча 2021 елның 1 апреленнән 15 июленә кадәр хәрби хезмәткә чакырылу көненә 18 яше тулган, шулай ук 1994-2002 елларда туган хәрби хезмәткә чакырылудан кичектерү вакыты чыккан гражданнага көзге чакырылыш үткәрергә.

Хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе эшен 2021 елның 1 апреленнән 9.00 сәгатьтән башларга.

2. Медицина тикшерүен «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ бинасында уздырырга, гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны Татарстан Республикасы Сарман һәм Мөслим районнарының хәрби комиссариатында үткәрергә.

2.1. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның сәламәтлеге торышына карата шикаятьләрне ачыклау өчен 2021 елның 22 марттан медицина тикшерүен оештырырга.

2.2. Медицина комиссиясе эшен түбәндәге срокларда оештырырга- хәрби хезмәткә чакырылучыларга медицина тикшерүен 2021 елның 1 апреленнән алып 15 июленә кадәр үткәрергә.

3. «Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибына, сыйфатлы медицина тикшерүе уздыру һәм хәрби хезмәткә чакырылучыларны дәвалау максатларында, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- РФ Кораллы Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнарга чиратсыз анализлар тапшыруны, күкрәк читлеген тикшерүне үткәрүне, йөрәк ЭКГсын төшерүне тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә яраклылыгын билгеләү максаты белән, хәрби хезмәткә чакырылучыларны стационар тикшерү өчен, үзәк район хастаханәсенең һәр бүлегендә 1-2 койка-урын бүлеп бирергә;

- Сарман һәм Мөслим районнарының хәрби комиссариатына авыруның амбулатор медицина карталарын (25 нче форма) һәм аларга кушымта итеп яшүсмер битләрен (25/У формасы) тапшырырга;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларны медицина тикшерүе өчен квалификацияле табиб-белгечләр:

**Төп состав:**

- Өлкән табиб - Шәмсетдинов И.А.
- терапевт - Шәмсетдинов И.А.
- отоларинголог - Мостаев Р.И.
- хирург – Әбдулазизов Ю.М.
- стоматолог- Сафина А.Н.
- невролог - Гайфиева Д.А.
- психиатр - Бишимов Т.Н.
- окулист - Гайнетдинова Н.Г.
- дерматолог - Латыйпов И.М.

**Резерв состав:**

- Өлкән табиб – Хәйртдинова Т.Н.
- терапевт - Хәйртдинова Т.Н.
- отоларинголог – Латыйпова Р.Р.( Сарман РҮХ)
- хирург - Ханов Р.Ф.
- стоматолог - Әхмәтханов С.М.
- невропатолог - Давлетбердина С.Р.
- психиатр – Әхкыямова Р.Р. (Сарман РҮХ)
- окулист - Ильясов И.И.
- дерматолог – Валеева Г.Ф.(Сарман РҮХ), шулай ук 22.03.2021 – 15.07.2021 елга кадәр 8 кеше күләмендә уртача медицина персоналы бүлеп бирергә.

4. Хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе әгъзаларын, табибларны һәм урта медицина персоналын хәрби хезмәткә чакыру пунктында эшләгән чорда төп эштән азат итәргә, алар биләп торган вазыйфаны һәм айлык хезмәт хакын саклап калырга һәм Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты тарафыннан тиешле хезмәт хакы түләргә.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы буенча бүлеге начальнигына:

- медицина һәм чакыру комиссиясен уздыру чорына хәрби хезмәткә чакыру пунктында тәртип тәэмин итү өчен полиция хезмәткәре бүлеп бирергә;

- хәрби хезмәткә чакырылудан качып йөрүче егетләрне эзләү буенча оператив чаралар үткәрү өчен эзләү төркеме төзергә (бердәм боерык нигезендә);

- Татарстан Республикасы җыелма пунктына хәрби хезмәткә чакырылучыларны озаткан көннәрдә, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариаты гаризасы буенча, график нигезендә, озатучылар арасында җәмәгать тәртибен саклау өчен, полиция нарядын бүлеп бирергә.

6. Предприятиеләр, оешмалар, барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләр, уку йортлары җитәкчеләренә, җирлек башлыкларына киңәш итәргә:

- гражданнарга Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына чакыру турында хәбәр итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларны хәрби комиссиягә һәм аларны хәрби хезмәткә озатканда үз вакытында һәм оешкан төстә килүләрен тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларны чакыру комиссиясенә алып барырга кешеләр йөртү өчен җиһазландырылган транспорт белән тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларны тантаналы озату оештырырга;

- хәрби хезмәт үтү өчен җибәрелгән чакырылучыларга чакыру кәгазе буенча акчалата исәп-хисап ясарга;

- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Сарман һәм Мөслим районнары буенча бүлегенә хәрби хезмәткә чакырылучыларны исерек хәлдә озату очракларына юл куймаска.

7. Сарман һәм Мөслим районнарының хәрби комиссарына, РФ Хәрби көчләренә чакырылырга тиешле хәрби хезмәткә чакырылучылар белән һөнәри-психологик сайлап алу комиссиясе белән берлектә, хәрби-һөнәри ориентацияне ачыклау һәм хәрби хезмәткә чакырылучыларны хәрби белгечлекләр төркемнәре буенча рациональ бүлү максатында һөнәри-психологик сайлап алу үткәрергә.

8. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә хәрби хезмәткә чакырылучыларга психологик ярдәм күрсәтү, аларны өйрәнү, суицид билгеләрен башлангыч стадиядә ачыклау һәм профилактикалау, хәрби хезмәтнең яңа шартларына тизрәк яраклашырга ярдәм итү өчен психолог җибәрергә.

9. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы һәм «мәдәният бүлеге» МКУ башлыгына 2021 елның көзендә хәрби хезмәткә чакырылырга һәм озатылырга тиешле гражданнарны җәлеп итеп, 2021 елның 23 апрелендә район күләмендә «Хәрби хезмәткә чакырылучы көне» үткәрергә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе рәисе урынбасары - ТР Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары М.Р. Бадретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**